**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**17.03.2020** **г. Казань** **№ 480**

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы 2018 елның 14 февралендәге 2753 номерлы расланган боерыгы нигезендә Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфасын биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле булган вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы 2018 елның 14 февралендәге 2753 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

икенче пунктагы унсигезенче, егерменче, егерме беренче, егерме бишенче абзацларны үз көчен югалткан, дип санарга.

2. Әлеге боерык үз көченә рәсми бастырылганнан соң керә һәм 2019 елның 27 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Министр М.Н.Садыйков